| | |
|---|---|
| СОВЕТ КОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАРАГУЖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |


| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 19.09.2017 | с. Коргуза | 29-126 |

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясы 1 пункты, Карагуҗа авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Карагуҗа авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның уртак инициативасын тәкъдим итергә:

«Сез 2018 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару мәсьәләсен хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

- 156600 сумга янгын депосы төзү, Карагуҗа авылы, Патрикеево, Егидерево авылы зиратларын киртәләү.

ӘЙЕ ЮК.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе С. А. Сакин